**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 19 маендагы 1555 номерлы карары**

**Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турында**

2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданнар бердәмлеген ныгыту буенча муниципаль программаны үтәү йөзеннән, Казанга багышланган яңа шигырьләр һәм поэмалар иҗат итүгә ярдәм итү, шагыйрьләргә булышу, аларның иҗади потенциалын ачу өчен уңайлы шартлар тудыру максатыннан **карар бирәм:**

1. 2025 елның 20 маеннан 31 декабренә кадәр Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын игълан итәргә.

2. Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турындагы Нигезләмәне (кушымта) расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсен Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын гамәлгә ашыру өчен җаваплы дип билгеләргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (А.И.Абзалов) Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрүгә бәйле булган 2 000 000,00 сум күләмендәге чыгымнарны (приз фонды –1 600 000 сум, җыентык бастыру – 400 000 сум) 2025 елда 2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданнар бердәмлеген ныгыту буенча муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет язмасында каралган акчалар кысаларында гамәлгә ашырырга.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 25 апрелендәге 1652 номерлы «Декоратив-гамәли сәнгать осталары өчен «Борынгы Казан легендалары һәм мифлары» темасына багышланган «Саумы, Казан!» /

«Здравствуй, Казань!» конкурсын үткәрү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның  19 маендагы
1555 номерлы карарына
кушымта

**Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен, шулай ук Конкурста катнашу кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе Конкурсны оештыручы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалата бүләк бирә торган вәкаләтле орган булып тора.

Конкурсның башкару органы булып Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге тора (алга таба – Оештыру комитеты).

1.3. Конкурста 18 яшькә җиткән эшкә сәләтле физик затлар катнаша ала.

1.4. Комиссия тарафыннан Конкурста җиңүчеләр дип танылган гражданнарга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән акчалата бүләкләр бирелә.

1.5. Гомуми суммасы 1 600 000 сум булган акчалата премияләр түләүгә чыгымнар Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәдәният идарәсенең 2025 елга бюджет язмасында каралган акчалар чикләрендә, 2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданнар бердәмлеген ныгыту буенча муниципаль программа кысаларында гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

Конкурсның төп максаты – Казанга багышланган яңа шигырьләр һәм поэмалар иҗат итүгә ярдәм итү.

Конкурсның төп бурычлары:

- шагыйрьләргә ярдәм итү, аларның иҗади потенциалын ачу өчен уңайлы шартлар тудыру;
- рус һәм татар телләрендә шигъриятне популярлаштыру;

- рус һәм татар телләрендә Казан турында шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын чыгару.

## III. Конкурсның этаплары

Конкурс өч этапта үткәрелә:

I этап – гаризалар һәм конкурс эшләрен кабул итү, 2025 елның 20 маеннан 15 августына кадәр;

II этап – комиссия әгъзалары тарафыннан конкурс эшләрен карап тикшерү, комиссия утырышы, беркетмә төзү, Конкурс җиңүчеләрен билгеләү, 2025 елның 16 августыннан 21 сентябренә кадәрге чорда;

III этап – җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү, 2025 елның 22 сентябреннән 31 декабренә кадәрге чорда.

## IV. Конкурсны үткәрү вакыты һәм тәртибе

4.1. Конкурс 2025 елның 20 маеннан 31 декабренә кадәр, бу көнне дә кертеп, үткәрелә.

4.2. Конкурсны игълан итү һәм үткәрү турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/analiticheskiy-otdel/dokumenty/) урнаштырыла.

Игъланда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- Конкурсны уздыру нигезләре һәм вакыты;

- Конкурста катнашу өчен әлеге нигезләмәнең 4.6 пункты нигезендә Оештыру комитетына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

- документларны һәм эшләрне кабул итү урыны, вакыты һәм сроклары;

- Конкурсны үткәрү этаплары;

- Конкурс буенча тулы мәгълүмат алырга мөмкин булган чыганак турында белешмәләр (телефон, факс номерлары, электрон почта адресы).

4.3. Бер катнашучы Конкурска Казан турында рус һәм татар телләрендә бердән артык булмаган шигырьләр циклын һәм Казан турында рус яки татар телләрендәге бер поэма тапшыра ала.

4.4. Конкурста катнашу өчен Казанга багышланган шигырьләр һәм поэмалар кабул ителә.

4.5. Конкурс эшләре гамәлдәге законнарга каршы килмәскә һәм аларда түбәндәгеләр булмаска тиеш:

- Россия Федерациясе законнарына, шул исәптән Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нормаларына, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында»гы федераль законга каршы килә торган текст, сюжетлар, сәхнәдәге затларның һәм персонажларның гамәлләре;

- кеше абруен кимсетә торган цензурасыз (норматив булмаган) лексика, сүзләр һәм фразалар, экспрессив һәм жаргон гыйбарәләр, яшерен реклама, тәмәке тартуны, утлы һәм салкын коралларны, шартлаткыч матдәләрне, шартлаткыч җайланмалар ясауны, алкоголь һәм наркотик матдәләр, кеше психикасына тискәре йогынтысы булган башка матдәләр куллануны күрсәтү;

- реаль адреслар һәм телефон номерлары, дини хәрәкәтләр турында мәгълүмат, шул исәптән дини символика, товар маркалары, товар билгеләре, хезмәт күрсәтү билгеләре, физик һәм юридик затлар атамалары һәм алар турында искәртүләр;

- экстремистик һәм террорчылык юнәлешендә пропаганда алып бару, террорчылыкны ачыктан-ачык аклау;

- текстта фашист атрибутикасы (свастика), кан, кешеләрнең һәм хайваннарның тән газапларын чагылдырган көчләү күренешләре, дискриминациянең теләсә нинди төре, вандализм, интим күренешләр, кешенең яисә кешеләр төркеменең абруен төшерүче теләсә нинди формада башка мәгълүмат, шулай ук балаларның сәламәтлегенә һәм (яки) үсешенә зыян китерергә мөмкин булган мәгълүмат сурәтләре. Авторлык хокукы турындагы законнарда рөхсәт ителгән чикләрдә әсәрләрдән өземтә китерүдән тыш, башка авторларның текстларыннан (плагиат) файдалану рөхсәт ителми.

Әлеге шартлар үтәлмәгән очракта, эш Конкурста катнашуга кабул ителми.

4.6. Катнашучылар Конкурска түбәндәгеләрне җибәрә:

- катнашу турында билгеләнгән формадагы гариза (1 номерлы кушымта);

- катнашучының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы (2 номерлы кушымта);

- конкурс эше (шигырьләр циклы һәм/яки поэма).

4.7. Конкурска 2025 елдан да иртәрәк иҗат ителмәгән, беркайда да бастырылмаган эшләр кабул ителә.

4.8. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башкалар) Конкурста катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түләнә.

4.9. Конкурста катнашу өчен гариза биргәндә, конкурс әсәрләре авторлары оештыручыга Конкурс барышында кабул ителгән конкурс эшләрен файдалануга бушлай аерым чикләүләргә ия булган интеллектуаль хокук бирә.

4.10. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- Конкурста катнашу турындагы гаризаны һәм конкурс эшен җибәргәндә, аларны тапшыру вакытын бозу;

- Конкурста катнашу турында гаризаның яки конкурс эшләренең әлеге нигезләмә таләпләренә туры килмәве.

## V. Конкурс номинацияләре

Конкурс 10 номинация буенча уздырыла:

- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә рус телендә Казан турында шигырьләр циклы»;
- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә рус телендә Казан турында шигырьләр циклы»;
- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә татар телендә Казан турында шигырьләр циклы»;
- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә татар телендә Казан турында шигырьләр циклы»;
- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә рус телендә Казан турында поэма»;
- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә рус телендә Казан турында поэма»;
- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә татар телендә Казан турында поэма»;
- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә татар телендә Казан турында поэма»;
- «Татар телендә оригиналь иҗек»;
- «Рус телендә оригиналь иҗек».

## VI. Гаризалар бирүгә һәм конкурс материалларын рәсмиләштерүгә карата таләпләр

6.1. Катнашу өчен гаризалар һәм материаллар бары тик saumykazan@mail.ru электрон адресына «“Саумы, Казан!” / “Здравствуй, Казань!” конкурсына» тамгасы белән кабул ителә. Гаризада автор турында (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган көне, эш яисә уку урыны, регалияләр (булган очракта), яшәү адресы, элемтә өчен телефоннары, электрон

адресы) белешмәләр күрсәтергә кирәк, шулай ук эшнең/эшләрнең исеме, аның/аларның иҗат ителгән вакыты һәм номинациясе. Конкурс эше Word форматында (Times New Roman шрифты, зурлыгы – 14, интервалы – 1,5) бирелә.

6.2. Конкурста катнашучы үзенең тапшырылган иҗат эшенең авторы булуын һәм беркемнең дә авторлык хокукларын бозмавын гарантияли.

6.3. Автор үзенең конкурс эшен югарыда күрсәтелгән электрон почта адресы буенча Конкурсны оештыру комитетына хәбәр итеп кире кайтарырга мөмкин.

6.4. Конкурста катнашучылар авторлык хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә җавап бирәләр.

6.5. Конкурста катнашучыларның эшләре рецензияләнми.

6.6. Конкурста катнашуга гаризалар бирү конкурс эшләрен Казан шәһәре Мэриясенең һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының рәсми битләрендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының мәдәният Идарәсе бүлегендә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) ачык кулланылышта урнаштыруга ризалык бирә, шулай ук Казан шәһәре Мэриясе оештырган чараларда әсәрләрне халык алдында укуга, массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати басмалар һәм публикацияләр чыгаруга, Конкурс йомгаклары буенча җыентык бастыруга, конкурс эшләре турында, Конкурста катнашучылар һәм җиңүчеләр турында белешмәләр таратуга ризалык булып тора.

## VII. Комиссияне формалаштыру тәртибе һәм аның вәкаләтләре

7.1. Конкурсны үткәрү өчен комиссия төзелә. Комиссия составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

7.2. Комиссия составына комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм 8 комиссия әгъзасы керә.

7.3. Комиссия үз эшчәнлеген әлеге нигезләмәгә таянып гамәлгә ашыра.

7.4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү максатыннан түбәндәге функцияләрне башкара:

- Конкурста катнашучыларның конкурс эшләренә (секретарьдан тыш) билгеләнгән критерийлар буенча һәрьяклы һәм объектив бәя бирә;
- Конкурска йомгак ясый һәм җиңүчеләрне (секретарьдан тыш) билгели.

7.5. Конкурс комиссиясе турыдан-туры катнашу формасында да, онлайн-режимда да эшли ала.

7.6. Комиссия рәисе:

- комиссияне җитәкли һәм аның утырышларында рәислек итә;
- комиссия эшен оештыра һәм координацияли;
- комиссия утырышларын үткәрү турында карар кабул итә;
- комиссия утырышларының көн тәртибен формалаштыра;
- Конкурсның бәяләү процедураларында катнаша.

7.7. Рәис булмаган очракта аны комиссия рәисе урынбасары алмаштыра.

7.8. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 өлеше катнашкан очракта тулы хокуклы дип санала.

7.9. Комиссия сәркатибе:

- комиссия әгъзаларына комиссия утырышлары турында хәбәр итә;
- Конкурста катнашучыларга Конкурсның вакыты, урыны, этапларны узу нәтиҗәләре турында хәбәр итә;
- комиссия утырышларына материаллар әзерли;
- комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара һәм рәсмиләштерә, комиссия карарларын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен терки, комиссия утырышлары беркетмәләреннән өземтәләр әзерли;
- комиссия утырышлары беркетмәләрен һәм башка материалларны саклауны тәэмин итә.
- бәяләү процедураларында катнашмый.

7.10. Комиссия әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы бу турыда әйтергә тиеш. Мондый очракта комиссия әгъзасы комиссия эшендә катнашмый.

## VIII. Эшләрне бәяләү һәм җиңүчеләрне билгеләү

8.1. Конкурсның оештыру комитеты:

- гариза-анкеталарны кабул итә һәм әлеге нигезләмәнең VI бүлегендә бирелгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә;
- нигезләмәгә туры килә торган бәяләү исемлеген һәм һәр критерий өчен бәя бирү схемасын үз эченә алган бәяләү кәгазен формалаштыра;
- Конкурс комиссиясенә катнашучыларның эшләрен һәм бәяләү кәгазьләрен тапшыра.

8.2. I этап нәтиҗәләре буенча Конкурсның Оештыру комитеты тарафыннан яшь категорияләренә һәм номинацияләренә бүленгән исемлекләр төзелә.

8.3. Конкурсның II этабы нәтиҗәсе булып җиңүчеләрне билгеләү тора.

8.4. Эшләр комиссия әгъзалары тарафыннан 10 баллы шкала нигезендә түбәндәге критерийлар буенча аерым-аерым бәяләнә (3 номерлы кушымта):

- әсәрнең Конкурс темасына туры килүе,
- әсәрнең оригинальлеге,
- шигырьнең метафоралылыгы, образлылыгы,
- рифманың төгәллеге (примитив һәм штамп рифмалар булмау).

8.5. Комиссиянең Конкурска йомгак ясау буенча утырышы, бәяләү тәмамланганнан соң, ике эш көне эчендә уздырыла.

8.6. Комиссия карарлары комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Конкурста җиңүчеләр комиссиянең һәр әгъзасы балларын стандарт кушу юлы белән билгеләнә.

8.7. Иң күп балл җыйган катнашучылар Конкурсның җиңүчеләре дип танила. Тавыш бирү нәтиҗәләрен санаганда тавышлар саны тигез булган очракта, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч тавыш булып тора.

8.8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышында рәислек итүче һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан өч эш көне дәвамында имзалана.

8.9. Комиссия беркетмәсе утырыштан соң 2025 елның 16 августыннан 21 сентябренә кадәр рәсмиләштерелә.

8.10. Комиссия әгъзасының турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул комиссия утырышы башланганчы бу турыда белдерергә тиеш. Мондый очракта әлеге комиссия әгъзасы комиссия эшендә катнашмый.

8.11. Комиссия карары катгый булып тора һәм яңадан каралмый.

8.12. Комиссия әгъзаларының бәяләү кәгазьләре ачыктан-ачык дөньяга чыгарыла яки игълан ителә алмый.

8.13. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат йомгак ясаганнан соң өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/analiticheskiy-otdel/dokumenty/) урнаштырыла.

8.14. Әлеге Нигезләмәгә таянып, Конкурс нәтиҗәләрен игълан иткән көннән алып бер ай дәвамында Комиссия беркетмәсе нигезендә, бүлеп бирелгән финанслар кысаларында, призерларга бер тапкыр акчалата түләү бирелә.

## IX. Конкурска нәтиҗәләр ясау һәм аның җиңүчеләрен бүләкләү

9.1. «Рус телендә оригиналь иҗек», «Татар телендә оригиналь иҗек» номинацияләреннән тыш, һәр номинациядә җиңүчеләр билгеләнә – I, II, III урыннар.

9.2. Конкурста җиңүчеләргә түбәндәге күләмдә акчалата премияләр тапшырыла:

- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә рус телендә Казан турында шигырьләр циклы»:

I урын – 70 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 50 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 30 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә рус телендә Казан турында шигырьләр циклы»:

I урын – 70 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 50 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 30 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә татар телендә Казан турында шигырьләр циклы»:

I урын – 70 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 50 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 30 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә татар телендә Казан турында шигырьләр циклы»:

I урын – 70 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 50 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 30 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә рус телендә Казан турында поэма»:

I урын – 100 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 80 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 60 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә рус телендә Казан турында поэма»:

I урын – 100 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 80 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 60 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь категориясендә татар телендә Казан турында поэма»:

I урын – 100 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 80 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 60 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «35 яшьтән өлкәнрәк яшь категориясендә татар телендә Казан турында поэма»:

I урын – 100 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

II урын – 80 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

III урын – 60 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «Татар телендә оригиналь иҗек»:

җиңүче – 20 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- «Рус телендә оригиналь иҗек»:

җиңүче – 20 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп).

9.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе Конкурста җиңүчеләргә бүләк акчасын түли, Россия Федерациясе Салым кодексының 24 статьясы нигезендә салым агенты булып тора һәм отыш суммасының 13 проценты күләмендә физик затлар керемена салына торган салымны түли. Шул ук вакытта Конкурсны оештыручы акчалата премия түләнә торган финалистка акчалата премияләр түләүгә бәйле рәвештә салым түләү турында законда каралган бурыч турында тиешенчә хәбәр итәргә тиеш.

9.4. Акчалата премияләр 2025 елның 22 сентябреннән 31 декабрена кадәрге чорда Конкурста җиңүчеләрнең исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә. Якларның ихтыярына бәйле булмаган шартларга бәйле рәвештә күчерү мөмкин булмаган очракта, акчалата премияләрне түләү тәртибе өстәмә рәвештә килештерелә.

9.5. Җиңүчеләр түләүне күчерү өчен гариза һәм документлар пакеты (паспорт, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры, мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры, счетның реквизитлары) бирә. Әлеге гариза нигезендә акчаларны күчерү гамәлгә ашырыла.

9.6. Җиңүчеләр ачыкланмаган очракта приз фондының калган өлеше җыентыкны бастыру чыгымнарын түләүгә җибәрелә.

9.7. Җиңүчеләргә бүләкләү көне һәм урыны турында, бүләкләү чарасын үткәрүгә кимендә өч көн кала, өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

9.8. Конкурс йомгаклары буенча конкурста җиңгән, шулай ук комиссиянең югары бәясен алган әсәрләрдән шигъри җыентык бастыру күздә тотыла.

Казанга багышланган «Саумы,
Казан!» / «Здравствуй,
Казань!» шигъри конкурсын
үткәрү турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(форма)

**Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!»**
**шигъри конкурсында катнашу өчен гариза**

| № т/б | Ф.И.А., туган көне, эш яисә уку урыны, регалияләр (булган очракта) | Номинация, (әсәр нинди телдә, авторның яше) | Әсәрнең / әсәрләрнең атамасы, иҗат итү датасы | Элемтә өчен мәгълүмат (телефон, электрон почта, адрес) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Казанга багышланган «Сәумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________
(адресы, шәхесне раслый торган төп документның сериясе, номеры,

_______________________________________________________________________
күрсәтелгән документ бирелгән дата һәм аны биргән орган турында белешмәләр)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә, конкурс уздыру һәм акчалата бүләкләү алу максатыннан, операторга – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына, җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (таратуны, бирүне, файдалану өчен рөхсәтне), шәхси үзенчәлекләрен бетерүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны кертеп, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларымны, атап әйткәндә, түбәндәге белешмәләрне (кирәклесенең астына сызарга) эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1) фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны (теркәлү һәм факттагы) буенча адресы, электрон почта адресы һәм телефон номеры турында мәгълүматларны кертеп, анкета белешмәләре;

2) сериясен, номерын, бирү датасын, документны биргән органның атамасын кертеп, паспорт яки шәхесне һәм гражданлыкны таныклый торган башка документ турында белешмәләр;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында белешмәләр;

4) мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС);

5) рәсми теркәлү урыны турында белешмәләр.

Шәхси мәгълүматларымны өченче як аша гына алып булган очракта, миңа, шәхси мәгълүматларны алуның максатларын, мөмкин булган чыганакларын һәм ысулларын күрсәтеп, бу хакта алдан хәбәр итәлергә һәм моның өчен шулай ук ризалык

алынырга тиеш.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Ризалык аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм, шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатына ирешкән яки аны язмача кайтарып алган билгесез вакытка кадәр гамәлдә була.

_____________________________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү көне: 2025 елның «____» _____________.

Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары күрсәткечләре**

| **Критерий атамасы** | **Баллар** | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **0 балл** | **1-3 балл** | **4-7 балл** | **8-10 балл** |
| Әсәрнең конкурс темасына туры килүе | Эш күрсәтелгән темага туры килми | Бәяләнергә тиеш түгел | Эш игълан ителгән темага тулысынча туры килми | Эш игълан ителгән темага туры килә |
| Әсәрнең оригинальлеге | Эш билгеләнгән таләпләргә туры килми | Бәяләнергә тиеш түгел | Эш билгеләнгән таләпләргә өлешчә туры килә | Эш билгеләнгән барлык таләпләргә туры килә |
| Шигырьнең метафоралылыгы, образлылыгы | Эш билгеләнгән таләпләргә туры килми | Бәяләнергә тиеш түгел | Эш билгеләнгән таләпләргә өлешчә туры килә | Эш билгеләнгән барлык таләпләргә туры килә |
| Рифманың төгәллеге (примитив һәм штамп рифмалар булмау) | Эш билгеләнгән таләпләргә туры килми | Бәяләнергә тиеш түгел | Эш билгеләнгән таләпләргә өлешчә туры килә | Эш билгеләнгән барлык таләпләргә туры килә |